Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

5 октябрь 2022 ел № 166

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторының, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларын, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларын, муниципаль берәмлекләрнең контроль - хисап органнары рәисләрен, Рәис урынбасарларын, аудиторларын айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфа окладлары арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы карары нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары, аудиторының, Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибе һәм шартлары турында» 2018 елның 11 маендагы 233 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 30 сентябрендәге 323 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 8 номерлы, 2021 елның 15 ноябрендәге 89 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 103 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 136 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләме

(сум)

| «Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесе | 35 874 |
| Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасары | 33 124 |

| | |
|---|---|
| Район Советы аппараты җитәкчесе | 33 124 |
| Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары | 32 526 |
| Җирле үзидарәнең башка органы җитәкчесе | 32 407 |
| Башкарма комитетның аппарат (эшләр идарәчесе) җитәкчесе | 30 135 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 29 417 |
| Идарә башлыгы, мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире), башкарма комитетның башка структур бүлекчәсе җитәкчесе | 24 634 |
| Идарә башлыгы урынбасары, мөстәкыйль бүлек башлыгы урынбасары (мөдире), башкарма комитетының башка структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасары | 20 329 |
| Район башлыгы ярдәмчесе, башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе, район башлыгы киңәшчесе, башкарма комитет җитәкчесе киңәшчесе | 20 329 |
| Башкарма комитетның идарә составындагы бүлек башлыгы | 20 329 |
| Сектор мөдире | 18 894 |
| Баш белгеч | 18 177 |
| Әйдәп баручы белгеч | 17 100 |
| 1 категорияле белгеч, 2 категорияле белгеч, белгеч | 15 307 |

1.2. 3 нче кушымтадагы таблицаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларын, Әлмәт муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисен, рәис урынбасарын, аудиторларын ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

(сум)

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме |
|---|---|
| Башлык | 36 366 |
| Башлык урынбасары | 32 728 |

| | |
|---|---|
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 32 728 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе урынбасары | 29 418 |
| Аудитор Контроль - хисап палатасы | 24 634» |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле елга җирле бюджетта каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Хамадьяров Р.Р.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов